**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Козяково-Челнинского**
**сельского поселения**
**Рыбно-Слободского**
**муниципального района**
Иванова ул., дом 26,
с., 422668

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**Казак-Чаллысы**
**авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**
Иванов урамы, 26нчы йорт,
Казак-Чаллысы авылы , 422668

Тел.: (8-4361) 32-310 факс: (8-4361) 32-310, эл.адрес: Kcn.Rs@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**7 декабрь, 2021 ел** **Казаклар Чаллысы авылы** **№ 11**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 2021 елның 30 июлендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 7 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 - 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Регламенттагы дәүләт адреслар реестрын алып баруга һәм федераль мәгълүмат адреслар системасын эксплуатацияләүгә бәйле булган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, “Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында” 2014 елның 19 декабрендәге 1221 номерлы карарына төгәл туры китереп кулланыла.”;

1.2. 1.5 пунктының 11 - 17 абзацларын тиңдәшле рәвештә 3 - 9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4 - 7 пунктчаларында “Башкарма комитет” сүзен “төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яисә Башкарма комитет” сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында “Башкарма комитет” сүзен “төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яисә Башкарма комитет” сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.4. пунктында “Башкарма комитетның структур бүлекчәсе” сүзләрен “муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет”сүзләренә алмаштырырга;

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 8 номерлы карары белән расланган Агачлар, куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газон сүтүгә рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында “агачларның, куакларның һәлакәтлелеге турында бәяләмә белән” сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2. 2.4.1. пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

2.3. 2.5.4. пунктын төшереп калдырырга;

2.4. 2.6.1. пунктының 4,5,7 пунктчаларында “Башкарма комитет” сүзен “Башкарма комитет яисә төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы” сүзләренә алмаштырырга;

2.5. 2.6.1. пунктының 6,11 пунктчаларында “Башкарма комитет” сүзен “Башкарма комитет яисә төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы” сүзләренә алмаштырырга;

2.6. 2.6.3. пунктында “Башкарма комитетның структур бүлекчәсе” сүзләрен “муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет”сүзләренә алмаштырырга;

2.7. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында “гаризада күрсәтелгән яшел утыртмаларны тикшерү нәтиҗәсендә яшел утыртмаларны (авария хәлендәге агачларны) сүтүнең зарурлыгы расланмау” сүзләрен төшереп калдырырга;

2.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында “(авария-торгызу эшләрен башкару белән бәйле яисә яшел утыртмаларны җимерү өчен бик кирәк очраклардан тыш (агачның, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен)” сүзләрен төшереп калдырырга;

2.9. 2.8.4 пунктында “2 нче кушымтада” сүзләрен “3 нче кушымтада” сүзләренә алмаштырырга;

2.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында “,шулай ук авария-торгызу эшләрен уздыру өчен яшел утыртмаларны кисүгә яисә яшел утыртмаларны җимерү өчен аеруча зарурлык булган хәлдә (агачның, авария хәлендәге агачларның аву

куркынычын бетерү өчен) рөхсәтнамә алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта)” сүзләрен төшереп калдырырга;

2.11. 3.5.2.3. пунктын төшереп калдырырга;

2.12. 3.5.5. пунктында “;авария-торгызу эшләрен уздырганда яисә яшел утыртмаларны җимерү өчен аеруча зарурлык булган хәлдә (агачның, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен) гариза бирүче муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта – ике эш көне” сүзләрен төшереп калдырырга;

2.13. Регламентка 2 нче кушымтада “Авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.” сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Карарны Татарстан Республикасы , Балык Бистәсе муниципаль районы, Казаклар Чаллысы авылы, Иванов урамы, 26 нчы йорт; Иванаево авылы, Калинин урамы,18 йорт; Бирдебәк авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт;Үри Чаллысы авылы, Гаврилов урамы, 24 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башлыгы И.С. Ананьев